# *Ахметов Фоат*



*Сугыш башланганда миңа 1 яшь кенә иде. Мин сугыш вакытларын хәтерләмим, шуңа күрә күп әйбер дә әйтә алмыйм. Әтине сугышка озаттылар. Сугыштан соң укырга кердем. Сугыш кырыннан авылга кайткан кешеләр булмады. Авыр вакытларда дәүләттән ярдәм булмады. Сугыштан соң да тормышлар бик авыр булды. Кукәрин ашадык, ипине чират торып алдык. Тагын нәрсә бар, шуны ашыйсың. Кузгалак, какы ашадык. Укыган кеше укыды инде.*

*Яшьләргә теләгем шул: әйбәт укысыннар, дөньялар тыныч булсын, әти-әниләрен тыңласыннар.*